# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов в Республике Татарстан отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан по предоставлению мер социальной поддержки**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
16 июля 2020 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Законом Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», Законом Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» регулирует отношения, связанные с наделением органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов в Республике Татарстан (далее – органы местного самоуправления) отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан по предоставлению мер социальной поддержки.

Статья 2. **Государственные полномочия Республики Татарстан, которыми наделяются органы местного самоуправления**

Органы местного самоуправления наделяются государственными полномочиями Республики Татарстан по предоставлению мер социальной поддержки в части обеспечения питанием обучающихся по образовательным программам основного общего и среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях (далее – государственные полномочия).

Статья 3. **Наименования муниципальных образований в Республике Татарстан, органы местного самоуправления которых наделяются государственными полномочиями**

Государственными полномочиями наделяются органы местного самоуправления следующих муниципальных образований в Республике Татарстан:

город Казань, «город Набережные Челны», Агрызский муниципальный район, Азнакаевский муниципальный район, Аксубаевский муниципальный район, Актанышский муниципальный район, Алексеевский муниципальный район, Алькеевский муниципальный район, Альметьевский муниципальный район, Апастовский муниципальный район, Арский муниципальный район, Атнинский муниципальный район, Бавлинский муниципальный район, Балтасинский муниципальный район, Бугульминский муниципальный район, Буинский муниципальный район, Верхнеуслонский муниципальный район, Высокогорский муниципальный район, Дрожжановский муниципальный район, Елабужский муниципальный район, Заинский муниципальный район, Зеленодольский муниципальный район, Кайбицкий муниципальный район, Камско-Устьинский муниципальный район, Кукморский муниципальный район, Лаишевский муниципальный район, Лениногорский муниципальный район, Мамадышский муниципальный район, Менделеевский муниципальный район, Мензелинский муниципальный район, Муслюмовский муниципальный район, Нижнекамский муниципальный район, Новошешминский муниципальный район, Нурлатский муниципальный район, Пестречинский муниципальный район, Рыбно-Слободский муниципальный район, Сабинский муниципальный район, Сармановский муниципальный район, Спасский муниципальный район, Тетюшский муниципальный район, Тукаевский муниципальный район, Тюлячинский муниципальный район, Черемшанский муниципальный район, Чистопольский муниципальный район, Ютазинский муниципальный район.

Статья 4. **Срок, на который органам местного самоуправления передаются государственные полномочия**

Государственные полномочия передаются органам местного самоуправления на неограниченный срок.

Статья 5. **Финансовые и материальные средства, передаваемые органам местного самоуправления для осуществления государственных полномочий**

1. Финансовое обеспечение переданных государственных полномочий осуществляется за счет субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан.

2. Общий объем субвенций для осуществления государственных полномочий и его распределение между муниципальными образованиями определяются

в соответствии с Методикой определения объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий Республики Татарстан по предоставлению мер социальной поддержки в части обеспечения питанием обучающихся по образовательным программам основного общего и среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, согласно приложению к настоящему Закону.

3. Объем субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий, устанавливается законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период.

4. Материальные средства, находящиеся в собственности Республики Татарстан, в случае необходимости обеспечения осуществления государственных полномочий, предусмотренных настоящим Законом, передаются в безвозмездное пользование органам местного самоуправления в соответствии с Перечнем передаваемых материальных средств.

Разработка Перечня передаваемых материальных средств, его утверждение и принятие решения о передаче материальных средств осуществляются органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений, на основании подготовленного с учетом предложений органов местного самоуправления обращения органа исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющего государственное управление в сфере образования.

5. Органам местного самоуправления запрещается использование финансовых средств, полученных на осуществление государственных полномочий, предусмотренных настоящим Законом, на другие цели.

### Статья 6. **Права и обязанности органов местного самоуправления при осуществлении государственных полномочий**

1. Органы местного самоуправления при осуществлении государственных полномочий имеют право:

1) дополнительно использовать собственные финансовые и материальные средства в случаях и порядке, предусмотренных уставом муниципального образования;

2) получать необходимую консультационную и методическую помощь в органах государственной власти Республики Татарстан по вопросам осуществления государственных полномочий;

3) издавать муниципальные правовые акты по вопросам осуществления государственных полномочий на основании и во исполнение положений настоящего Закона;

4) обжаловать в судебном порядке письменные предписания органов исполнительной власти Республики Татарстан по устранению нарушений,

допущенных органами местного самоуправления в ходе осуществления государственных полномочий.

2. Органы местного самоуправления при осуществлении государственных полномочий обязаны:

1) определить органы местного самоуправления и должностных лиц органов местного самоуправления, ответственных за осуществление государственных полномочий;

2) соблюдать законодательство в области социальной поддержки населения, а также нормативные правовые акты органов исполнительной власти Республики Татарстан, принятые в пределах их компетенции, по вопросам осуществления государственных полномочий;

3) использовать по целевому назначению финансовые средства, выделяемые из бюджета Республики Татарстан, и государственные материальные средства, передаваемые на осуществление государственных полномочий;

4) представлять в орган исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющий государственное управление в сфере образования, отчеты об осуществлении государственных полномочий;

5) обеспечивать необходимые условия для осуществления уполномоченными органами исполнительной власти Республики Татарстан контроля за осуществлением переданных государственных полномочий;

6) устранять нарушения, выявленные при проведении контроля за осуществлением государственных полномочий;

7) возвратить неиспользованные финансовые и материальные средства в случае прекращения осуществления государственных полномочий.

Статья 7. **Права и обязанности органов государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий**

1. Органы государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий имеют право:

1) координировать в пределах своей компетенции деятельность органов местного самоуправления по вопросам осуществления государственных полномочий;

2) изучать, обобщать, распространять опыт работы органов местного самоуправления по осуществлению государственных полномочий;

3) давать письменные предписания по устранению нарушений, допущенных органами местного самоуправления или их должностными лицами в ходе осуществления государственных полномочий;

4) запрашивать в установленном порядке от органов местного самоуправления необходимую информацию и документы, связанные с осуществлением государственных полномочий.

2. Органы государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий обязаны:

1) обеспечивать передачу органам местного самоуправления финансовых и материальных средств, необходимых для осуществления государственных полномочий;

2) давать разъяснения и оказывать консультационную и методическую помощь органам местного самоуправления по вопросам осуществления государственных полномочий;

3) предоставлять органам местного самоуправления по их запросам необходимые материалы и документы, связанные с осуществлением ими государственных полномочий;

4) осуществлять контроль за осуществлением органами местного самоуправления государственных полномочий, использованием предоставленных на эти цели финансовых и материальных средств.

### Статья 8. **Порядок отчетности органов местного самоуправления об осуществлении государственных полномочий**

Отчеты об осуществлении государственных полномочий, переданных органам местного самоуправления, представляются органами местного самоуправления в орган исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющий государственное управление в сфере образования, ежеквартально до 10 числа месяца, следующего за отчетным кварталом, по форме, установленной Кабинетом Министров Республики Татарстан.

### Статья 9. **Контроль за осуществлением органами местного самоуправления переданных им государственных полномочий**

Контроль за осуществлением государственных полномочий, переданных органам местного самоуправления, осуществляется:

1) органом исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющим государственное управление в сфере образования, в части надлежащего исполнения государственных полномочий путем:

запросов необходимых документов, отчетов и информации об исполнении государственных полномочий;

проведения проверок в порядке, предусмотренном статьей 77 Федерального закона от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации»;

2) органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области финансовой политики, в части использования финансовых средств, предоставленных для осуществления государственных полномочий, в соответствии с бюджетным законодательством Российской Федерации и иными нормативными правовыми актами, регулирующими бюджетные правоотношения;

3) в случае передачи в безвозмездное пользование органам местного самоуправления материальных средств, находящихся в собственности Республики

Татарстан, для обеспечения государственных полномочий, предусмотренных настоящим Законом, органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений, в части сохранности и надлежащего использования государственного имущества, переданного органам местного самоуправления для осуществления государственных полномочий, путем:

запросов необходимых документов, отчетов и информации об исполнении государственных полномочий;

проведения проверок в порядке, предусмотренном статьей 77 Федерального закона от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации»;

принятия необходимых мер по устранению нарушений и их предупреждению.

Статья 10. **Условия и порядок прекращения осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий**

1. Прекращение осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий производится законом Республики Татарстан в случае:

1) неисполнения или ненадлежащего исполнения органами местного самоуправления требований законодательства по осуществлению государственных полномочий;

2) неисполнения органами местного самоуправления и их должностными лицами предписаний об устранении нарушений настоящего Закона;

3) изменения федерального законодательства или законодательства Республики Татарстан, в результате которого исполнение органами местного самоуправления государственных полномочий становится невозможным;

4) в иных случаях, предусмотренных законодательством.

2. Прекращение осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий влечет за собой возврат неиспользованных финансовых и материальных средств, переданных для осуществления государственных полномочий.

3. В случае неисполнения или ненадлежащего исполнения органами местного самоуправления требований законодательства по осуществлению государственных полномочий орган исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющий государственное управление в сфере образования, в течение 10 дней со дня выявления указанных нарушений направляет в органы местного самоуправления предписание об их устранении.

4. Предписание об устранении выявленных нарушений подлежит обязательному рассмотрению не позднее чем в десятидневный срок со дня его поступления в орган местного самоуправления. О результатах рассмотрения предписания в течение одного рабочего дня сообщается в письменной форме в орган исполнительной власти Республики Татарстан, направивший предписание.

5. В случаях, предусмотренных частью 1 настоящей статьи, орган исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющий государственное

управление в сфере образования, вносит на рассмотрение в Кабинет Министров Республики Татарстан предложение о прекращении осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий и соответствующий проект закона Республики Татарстан.

Статья 11. **Заключительные положения**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2021 года.

2. Нормативные правовые акты органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан подлежат приведению в соответствие с настоящим Законом в течение трех месяцев со дня вступления его в силу.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
21 июля 2020 года
№ 48-ЗРТ

Приложение
к Закону Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов в Республике Татарстан отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан по предоставлению мер социальной поддержки»

**Методика**
**определения объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий Республики Татарстан по предоставлению мер социальной поддержки в части обеспечения питанием обучающихся по образовательным программам основного общего и среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях**

1. Настоящая Методика предназначена для определения объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов (далее – муниципальных образований) из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий Республики Татарстан по предоставлению мер социальной поддержки в части обеспечения питанием обучающихся по образовательным программам основного общего и среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях (далее – государственные полномочия).

2. Общий объем субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований для осуществления государственных полномочий ($S_{ob}$), определяется по формуле:

$$S_{ob} = \sum_{i=1}^{n} S_i,$$

где:

$S_i$ – объем субвенции, предоставляемой бюджету i-го муниципального образования;

n – число муниципальных образований, наделенных государственными полномочиями.

3. Объем субвенции, предоставляемой бюджету i-го муниципального образования, определяется по формуле:

$S_i = Ч_i \times Р \times Д$,

где:

$Ч_i$ – фактическая численность обучающихся в муниципальных общеобразовательных организациях по образовательным программам основного общего и среднего общего образования по состоянию на 1 сентября года, предшествующего планируемому;

Р – стоимость питания в день за счет средств бюджета Республики Татарстан на одного обучающегося в период обучения, ежегодно утверждаемая Кабинетом Министров Республики Татарстан;

Д – количество дней питания одного обучающегося в год в период обучения, за исключением каникулярного времени, выходных и нерабочих праздничных дней, при шестидневной учебной неделе, планируемое органом исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющим государственное управление в сфере образования, в соответствии с требованиями федеральных государственных образовательных стандартов.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 16 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү белән бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем алучыларның туклануын тәэмин итү өлешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә.

3 статья. **Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган муниципаль берәмлекләрнең исемнәре**

Дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасында түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирелә:

Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган чор**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре чикләнмәгән чорга бирелә.

5 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырыла торган финанс чаралары һәм матди чаралар**

1. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен субвенцияләрнең гомуми күләме һәм аны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү, әлеге Законга кушымтага нигезләнеп, Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем алучыларның туклануын тәэмин итү өлешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан

муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен билгеләү методикасы нигезендә башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Җирле үзидәрә органнарына әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларын башка максатларга файдалану тыела.

6 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә рәвештә үз финанс һәм матди чараларыннан файдаланырга;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында кирәкле консультатив һәм методик ярдәм алырга;

3) әлеге Закон нигезләмәләре нигезендә һәм аларны үтәү максатыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар кабул итәргә;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары тарафыннан хокук бозуларны бетерү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының язма күрсәтмәләренә суд тәртибендә шикаять бирергә.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы җирле үзидарә органнарын һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын билгеләргә;

2) халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендәге законнарны, шулай ук дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив хокукый актларын үтәргә;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан һәм дәүләт матди чараларыннан максатчан юнәлештә файдаланырга;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисапларны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органына тапшырырга;

5) тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тикшерүне башкару өчен кирәкле шартлар тәэмин итәргә;

6) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшерү вакытында ачыкланган хокук бозуларны бетерергә;

7) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру туктатылган очракта файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди чараларны кире кайтарырга.

7 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләре гамәлгә ашырылганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләре гамәлгә ашырылганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген үз компентенциясе чикләрендә җайга салырга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эш тәҗрибәсен өйрәнергә, гомумиләштерергә, таратырга;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары яисә аларның вазыйфаи затлары тарафыннан хокук бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләр бирергә;

4) җирле үзидарә органнарыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле кирәкле мәгълүматны һәм документларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләре гамәлгә ашырылганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларын һәм матди чараларны җирле үзидарә органнарына тапшыруны тәэмин итәргә;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарына аңлатмалар бирергә һәм консультатив һәм методик ярдәм күрсәтергә;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле кирәкле материалларны һәм документларны җирле үзидарә органнарына аларның соратып алуы буенча тапшырырга;

4) җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләренең гамәлгә ашырылуын, әлеге максатлар өчен бирелгән финанс чараларыннан һәм матди чаралардан файдалануны тикшереп торырга.

8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.

9 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләренең алар тарафыннан гамәлгә ашырылуын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләренең алар тарафыннан гамәлгә ашырылуын тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләренең тиешенчә үтәлүе өлешендә түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алу;

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 77 статьясында каралган тәртиптә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан, Россия Федерациясе бюджет законнарына һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларга нигезләнеп, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан файдалану өлешендә;

3) Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырылган очракта – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт милкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең милкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алу;

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 77 статьясында каралган тәртиптә тикшерүләр үткәрү;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.

10 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны туктату түбәндәге очракта Татарстан Республикасы законы белән башкарыла:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләре җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлмәгәндә яисә тиешенчә үтәлмәгәндә;

2) әлеге Законны бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан үтәлмәгәндә;

3) дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәү мөмкинлеге юкка чыгарырлык итеп федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары үзгәртелгәндә;

4) законнар белән каралган башка очракларда.

2. Дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны туктату файдаланылмаган финанс чараларын һәм дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән матди чараларны кайтарып бирүне таләп итә.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы әлеге хокук бозулар ачыкланганнан соң 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрә.

4. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органына кергән көннән соң ун көннән дә соңга калмаган чорда һичшиксез каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең күрсәтмәне җибәргән органына бер эш көне эчендә язма рәвештә хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны туктату турындагы тәкъдимен һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертә.

11 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 21 июль
№ 48-ТРЗ

«Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

**Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем алучыларның туклануын тәэмин итү өлешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен билгеләү методикасы**

1. Әлеге Методика муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем алучыларның туклануын тәэмин итү өлешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен каралган.

2. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме ($S_{ob}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_{ob} = \sum_{i=1}^{n} S_i,$$

монда:

$S_i$ – i-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме;

$n$ – дәүләт вәкаләтләре бирелгән муниципаль берәмлекләр саны.

3. I-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$Si = Чi \times Р \times Д$,

монда:

Чi – муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем алучыларның планлаштырган елның алдагы елының 1 сентябренә булган факттагы саны;

Р – Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән укыту чорында бер белем алучының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган бер көнгә туклану бәясе;

Д – алты көнлек уку атнасында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә планлаштырыла торган туклану көннәренең уку чорында елына бер белем алучыга туры килә торган саны, моңа каникуллар вакыты, ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәре керми.